СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.10.2022 г. с. Шеланга № 22-116

Шилангы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Байрак торак пункт территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пункты территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июленнән № 45-ЗРТ Федераль законның 35 ст. , Шилангы авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Гражданнарның яшәвенең түбәндәге территорияләре чикләрендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

Кызыл Байрак авылы:
Сосновый урамында 1 нче һәм 15 нче йортлар;
Урман урамында 1нче һәм 16нчы йортлар;
Идел буе урамында №1-17 номерлы йортлар;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча Шилангы авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә

3. Әлеге карарны Югары Ослан авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров